**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 2** **12.11.2019**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районыЧалпы авыл җирлеге составына керүче, Чалпы авылында 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлегендә гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Чалпы авыл җирлеге Чалпы торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- Чалпы авылында Ленин, Яшьләр, Садовая, Новая, Гагарин, Казан урамнары буенча вак таш җәелгән юлларның чокырларын ямау (ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Чалпы авылында урамнарны яктырту өчен яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампалар урнаштыру, эшләр өчен түләү;
- Чалпы авылы зиратлары өчен җиһазлар һәм инвентарь (генератор, отбойный чүкеч) сатып алу;
- Чалпы авылында янгын сүндергечләр, янгын сундерү ранецлары, янгынга каршы инвентарь сатып алу;
- Чалпы юлларын кардан чистарту;
- Чалпы авылы территориясен җәйге чорда чабу;
- Чалпы авылында коры агачлар, куакларны кисү;
- Чалпы авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);
- Чалпы авылында һәлак булган сугышчыларга куелган һәйкәлләрне ремонтлау (койма урнаштыру, буяу, агарту, килешү буенча эш өчен түләү) ;
- Чалпы авылында һәйкәл (мемориаль такталар) урнаштыру;
- Чалпы авылында урам исемнәре язылган табличкалар әзерләү;
- Чалпы авылындагы гидротехник корылма янында «су коенырга ярамый» дигән табличкалар ясау, урнаштыру;
- Чалпы авылында «Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында

урнаштырырга: ТР, Азнакай муниципаль районы, Чалпы авылы, Ленин урамы, 130 йорт; ТР, Азнакай муниципаль районы, Чалпы авылы мәктәп бинасында мәгълүмат стенды, ТР, Азнакай муниципаль районы, Чалпы авылы,Үзәк урам, Чалпы амбулаториясе бинасында үзәк мәгълүмат стенды, ТР, Азнакай муниципаль районы, Чалпы авылы, Үзәк урам, 39 йорт.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чалпы авыл җирлеге Башлыгы: А.М. Мөхәмәтшин